# *Әти-әниләр өчен консультация*

## *“Ризаэддин Фәхреддин —*
## *күренекле шәхес һәм аның мирасы”*

*(Федераль Дәүләт таләпләреннән  чыгып әхлак тәрбиясе бирү)*

Әлмәт шәһәре

Хөрмәтле әти-әниләр!

Тәрбияле бала үстерим дисәң: нишләргә, эшне нәрсәдән башларга, нинди чыганакларга таянырга? Бүгенге чыгышымда мин сезне язучы, дин галиме, мөхәррир, мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин мирасы белән таныштырып, бу сорауга җавап табарга тырышырмын.

Ул 1859 нчы елның 17 гыйварында Татарстанның Әлмәт районы Кичүчат авылында рухани гаиләсендә дөньяга килгән. Ризаэддин бине Фәхреддин мәдрәсәдә укыган елларында ук бик күп китаплар укый, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә ана телен яхшы белгән кебек иркен сөйләшерлек һәм язарлык тирән белем ала. Үзе мәдрәсәдә укыганда ук ул башлангыч сыйныф балаларын укыта башлый. Ул укыту-тәрбия эшендә яңа алымнар куллануы белән бик тиз танылып өлгерә. Мәдрәсәне тәмамлагач, ул укыту эше белән тулаем шөгыльләнә башлый. Аның бу эшендә мәшһүр мәгърифәтче, галим, педагог Ш.Мәрҗани алымнарының көчле тәэсире сизелә

Ул мәдрәсәләрдә укытыр өчен бер-бер артлы дүрт китап язып бастырып чыгара. Һәр эшендә яңалык кертергә омтыла. Ул татар мәктәп-мәдрәсәләре челтәрендә реформа үткәрүне үзе күзаллаганча тасвирлап һәм күпсанлы дәлилләр белән фикерен раслап зур күләмле хезмәт язып, шуны бастырып таратуга рөхсәт сорап Санкт-Петербургка җибәрә. Ләкин аның якты хыяллары тормышка ашмый кала. Патша цензурасы аңа рөхсәт бирми.

Ризаэддин Фәхреддин татар халкының аң-белем, мәдәният һәм мәгърифәт дәрәҗәсен үстерү, күтәрү өчен аның мәктәпләрендә реформа үткәрү турында үзенең тәгъдимнәрен яза.

Балаларны тәрбияләр өчен, — дип яза ул, ике төрле эшкә ихтыяҗыбыз бардыр. Беренчесе — балаларның үзләренә хас — ир балалар һәм кыз балалар өчен аерым-аерым мәктәпләр кирәк дип яза. Шулай ук бөек галим, Ризаэддин Фәхреддин безгә мәңге онытылмаслык шундый нәсыйхәт язып калдырган: “Балачакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас.”

Бүген без сезнең белән аның “Тәрбияле бала” исемле балаларны тәрбияләү турындагы, бик акыллы киңәшләре белән танышырбыз.

Бу киңәшләрне үзегезне, балаларыгызны тәрбияләгәндә исегездән чыгармагыз, тормышта кулланырсыз дип уйлыйм.

Балаларны тәрбияләргә иң кечкенә чакларыннан башлагыз, аларның күңелләренә күркәм холык орлыклары чәчегез, адәмчелекне вә изгелек ничек булганын белдерегез, урынына карап, бераз йомшаклык, вә вакытына карап, бераз катылык та күрсәтегез, ләкин куркытып түгел, бәлки киңәш чишмәсе икәнен аңлап, сүзләрегез белән гамәл кылачаклар булыр кадәр, үзегезне олы итеп тота белегез.

Балагыз күз алдында үз-үзегезне хөрмәтле тотыгыз, алар сездән үзләрен тотарга өйрәнсеннәр, гаилә эчендә шуңа бердәмлек вә мәхәббәт нык булыр. Балаларыгызга һич ялган сөйләмәгез, аларга яман дога кылмагыз, бу

нәрсәләр исә балаларны ялган сөйләргә өйрәтер, вә атаның хөрмәтен киметер.

Хатыннарыгыз тәрбияләргә керешкәндә балаларның араларына кермәгез, сез тәрбияләгәндә хатыннарыгыз да арагызга кермәсен. Бу нәрсә тәрбия түгел, тәрбиясезлектер, чөнки бу хәлне күреп, үзен кыерсытылган итеп санар һәм иркәлеккә өйрәнеп, һичбер тәрбия алмыйча, ата белән ана арасында бер-берсеннән качып, шикаять итеп йөрер.

Бу дөньяда адәмнәрнең кыйммәтләре — фәкать үз тырышлыклары белән булганлыгын, һәркем үз эшен үзе күрергә бурычлы икәнлеген балагызга аңлатыгыз, кешегә таянырга, фәкать бәхет һәм хаер догаларга ышанып торырга өйрәнмәсеннәр.

Балаларыгыз өчен мал җыеп та тәрбияләрен ташламагыз, бәлки малны аларның тәрбияләре юлына сарыф итегез. Бетми торган мирас — гүзәл тәрбия икәнен белегез. Дөрес тәрбия булмавы соңында балалар өчен дөнья тулы алтын калса да файдасы юктыр, бәлки тәрбиясезлекләре — бер бәхетсезлектер вә аның өстенә калган алтыннары — икенче бәхетсезлек булыр.

Гаделлек һәм инсафлык өйрәтү өчен, хаҗәтләрен үтәгәндә вә кирәкләрен булдырганда барысын бертигез күрегез, бүләк биргәндә барчасына да тигез бирегез, берсенә яшерен бер нәрсә биреп тә “Сак бул, туганнарыңа белдермә!” дигән кебек нәрсәләрдән сакланыгыз, чөнки болай итү — аларга җәбер золым, алдау, хыянәт кебек нәрсәләрне өйрәтер. Саранлык һәм үз-үзеңне сөю кебек бозыклык орлыкларын күңелләренә чәчәр.

Көчләре җитешерлек булганда, балаларыгызга үз эшләрегезне һәм һөнәрләрегезне өйрәтегез, фикерләрегез белән бүлешегез, дөнья көтү өчен аларның күзләрен ачыгыз, тормыш кагыйдәләрен аңлатыгыз, акылларын нурландырыгыз.

Балаларыгызны кеше дип санап, аларның адәм булуларын теләгез, аналары белән гүзәл шәригать әдәбе белән мөгаләмә итегез. Бала мәхәббәте - ата белән ана арасында уртак икәнен балаларыгызга гамәлләрегез белән белдерегез. Әгәр дә алар сездән мондый нәрсәләрне күреп үссәләр, үзләре дә сездән алган гыйлем һәм тәрбияне үз хатыннарына, үз балаларына күрсәтерләр. Вакыты җитү белән әдәп өйрәтегез.

Балаларыгызны артык иркәләмәгез, һәрнәрсәне алар ихтыярына куймагыз, алар алдында яман сүзләр сөйләмәгез, сүгенмәгез!

Куркак булып үсмәсеннәр өчен, аларга төрле куркыныч әйберләр сөйләмәгез. Балаларыгыз алдында үзегезне әдәпле тотыгыз.

Балаларыгыз мөстәкыйль дөнья көтәргә өйрәнсеннәр өчен аларга төрле һөнәрләр өйрәтегез, чөнки эшсез һәм ялкау балалар үзләренә дә башкаларга да бернинди файда китермиләр.

Баланың ата-ананы карап, аларның хакын үтәве никадәр зур һәм мөһим булса, баланың ата-ана өстендәге хакы да шулкадәр зур һәм мөһим. Ата-ана булган кеше үзләренең өсләрендәге бала хакларын да тиешенчә үтәргә тиешләр. Ата-ана иң элек балага күркәм исем куярга тиеш. Аннан соң баланы дөрес итеп тәрбия итәргә кирәк. Яшь вакытында тәрбия алмаган бала

зурайгач яхшы кеше була алмый. Бабайлар әйтмешли, ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән кермәс. Аннан соң, оясында ни күрсә, очканында шуны куар. Бабайларның бу сүзләре бик мәгънәле сүзләр, алар аны ачынмыйча гына әйтмәгәннәр, бала дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле булсын өчен аны бигрәк тә яшь чагында карарга кирәк. Өстен-башын кулдан килгән кадәр пакъ тотарга, вакытында ашатып тамагын туйдырырга тиешле, вакытында йоклатырга кирәк. Аннан соң балаларны яшь вакытта елатып уйнамаска, һичбер вакытта куркытмаска, орышмаска, кул белән сукмаска кирәк. Комачаулана башласа, тәмле тел белән йомшак кына юатырга кирәк. Шулай булганда, бала үпкәләүчән, тыңлаусыз, холыксыз, йөрәксез булып үсәр. Азрак аңлый һәм сөйләшә башласа, аның алдында ярамас эшләр эшләү, әдәпсез сүзләр сөйләү, ачыланышу кебек нәрсәләр булмаска тиеш. Аны һичбер вакытта ялгыз калдырмаска, кызу һәм салкын урыннарда тотудан сакланырга кирәк. Үсә башлагач, әдәпсез балалар белән катыштырмаска, начар уеннар уйнаудан сакларга кирәк. Шулай ук, балаларга берәр нәрсә хакында алдап сөйләүдән, кулдан килмәс эшне кушудан, артык иркәләп холкын бозудан сакланырга кирәк. Балалар җиде яшьләренә җиткәч, аларны укытырга бирергә кирәк. Баланы вакытында укытмый калдырдыңмы, аннан соң аңардан һичбер игелек көтәргә, аны бәхетле итәм дип тырышырга ярамый.

Җәй көннәрендә һәрвакыт янында йөртеп, кыз бала булса анасы, ир бала булса атасы дөнья эшләрен һәркайсын бөртекләп өйрәтергә, мөмкин булса берәр һөнәр дә өйрәтергә кирәк.

Хайваннарның балалары колаклары киселеп тумаганнары кебек, һәрбер адәм баласы саф табигатьтә һәм һәртөрле гөнаһ нәрсәләрдән азат хәлдә дөньяга килә. Соңыннан шул баланы ата-анасы тәрбия итә.

Кечкенәләребезгә мәрхәмәт күрсәтмәүче һәм олыларыбызның хакларын үтәмәүче кеше бездән түгел. Җәмгыятьнең төзек булуы олыларны кадерләү һәм кечкенәләргә карата мәрхәмәтле булуга нигезләнгән.

Кечкенәләргә мәрхәмәтле булу — аларны һәрвакыт иркәләп тору дигән сүз түгел, бәлки аларга шәфкать юлы белән әдәп-тәрбия бирү, дини һәм дөньяви кирәкләрне өйрәтүдер. Һичбер ата-ана үзенең баласына яхшы тәрбия бирү, әдәп-әхлак өйрәтүдән дә артыграк бүләк бирә алмас.

Бала ак кәгазь кебек, аңа төрле нәрсә язарга мөмкин. Шуңа күрә ул яхшы тәрбияне дә, яман юлга алып бара торган бозык тәрбияне дә кабул итәргә мөмкин. Вакытында чарасын күреп, балага яхшы тәрбия бирү, аны яман юллардан саклау — ата-ананың баласына бирә ала торган бүләкләренең иң кыйммәтлесе. Балалар дөнья тормышының зиннәте булып торалар. Алар тормышны тагын да күңеллерәк итәләр һәм алар аркылы шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек күбәя. Әгәр ата-аналар үзләренең балаларын игелекле итеп үстерсәләр, ул вакытта алар тормышның бизәге булалар. Әгәр балаларын тәрбияләүгә тиешле игътибарны бирмәсәләр, ул вакытта алар зур бәхетсезлек, бәла-каза, газап һәм бетмәс мәшәкать тынычлыгын бетерүгә сәбәп булалар. Ата-аналар үзләре дөньяга китергән балалар алдында зур җаваплылык тотканлыкларын яхшы аңларга тиешләр.